**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА ТРОИЦКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«05» апрель 2016 ел № 04

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы башлыгы белән төзелгән 2016 елның 04 апрелендәге килешү нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Яңа Троицк авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:
   - Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы башлыгының 2016 елның 24 февралендәге 20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы башлыгының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җыю һәм җибәрү буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче

җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының үзара эшчәнлек регламентына таянырга;

- муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында регистрга кертелергә тиешле белешмәләрне район башкарма комитетына җибәрү өчен җаваплы затларны билгеләргә;

- - регистрны оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка чаралар күрергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм районның рәсми сайтында урнаштырыга.
3. Әлеге карар үәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам..

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Р. Волкова